# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципал районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында
гражданнардан үзара салым кертү турында

**14.12.2021 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципал районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Кәрәкәшле торак пунктында зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында су юлын ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алмаштыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

Кәрәкәшле торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү (килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктындагы Комсомол урамында җәяүлеләр басмасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу).

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

Җыенда рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев